**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

27.01.2020 № 21

**Антлы утырышчы булуга кандидатлар исемлекләрен һәм запас исемлекләрен тикшерү турында**

«Россия Федерациясендә федераль гомуми юрисдикция судларының антлы утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә:

1. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына:

Татарстан Республикасы район (шәһәр) судлары эшен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Президентының «2018 елның 1 июненнән 2022 елның 31 маена кадәрге чорга федераль гомуми юрисдикция судлары эшен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре антлы утырышчылары кандидатлары исемлекләрен һәм запас исемлекләрен төзү турында» 2018 елның 29 гыйнварындагы 93 номерлы боерыгы нигезендә төзелгән антлы утырышчы булуга кандидатлар исемлеген һәм запас исемлеген (алга таба – район (шәһәр) судлары өчен исемлекләр һәм запас исемлекләр), шулай ук Үзәк округ хәрби суды эшен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Президентының «2019 елның 1 июленнән 2023 елның 30 июненә кадәрге чорга Үзәк округ хәрби суды эшен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре антлы утырышчылары кандидатлары исемлекләрен һәм запас исемлекләрен төзү турында» 2019 елның 18 маендагы 179 номерлы боерыгы нигезендә төзелгән антлы утырышчы булуга кандидатлар исемлеген һәм запас исемлеген (алга таба – Үзәк округ хәрби суды өчен исемлекләр һәм запас исемлекләр), аларда антлы утырышчы булу хокукын югалткан гражданнарны, фамилиясен һәм тиешле муниципаль берәмлек чикләрендә яшәү урынын алыштырган гражданнарны ачыклау өчен тикшерү уздырырга;

район (шәһәр) судлары өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә, шулай ук Үзәк округ хәрби суды өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә кертү өчен өстәмә рәвештә сайлап алынган гражданнарга хәбәр итәргә һәм аларга ике атна эчендә күрсәтелгән исемлекләр белән танышу мөмкинлеге бирергә, шулай ук гражданнарның аларны исемлекләрдән төшереп калдыру һәм әлеге исемлекләрдәге антлы утырышчы булуга кандидатлар турындагы төгәл булмаган мәгълүматларны төзәтү турында язма гаризаларын карап тикшерергә;

2020 елның 20 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Президентына әлеге боерыкка кушымтада бирелгән форма буенча тутырылган, Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы кул куйган хат теркәлгән, Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша MS Excel форматындагы файллар теркәлгән электрон документ рәвешендә, ә 2020 елның 10 апреленә кадәр – Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы кул куйган һәм мөһер сугылган кәгазь чыганакта район (шәһәр) судлары өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә, шулай ук Үзәк округ хәрби суды өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр юлларга;

2020 елның 10 апреленә кадәр Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы (шәһәр округы) территориясендә юрисдикция хокукы булган район (шәһәр) судына әлеге боерыкка кушымтада бирелгән форма буенча төзелгән, кәгазь чыганактагы Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы кул куйган һәм мөһер сугылган район (шәһәр) судлары өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә үзгәрешләр һәм өстәмәләр юлларга;

«Россия Федерациясендә федераль гомуми юрисдикция судларының антлы утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы 10 өлеше нигезендә массакүләм мәгълүмат чараларында район (шәһәр) судлары өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә, шулай ук Үзәк округ хәрби суды өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне бастырып чыгаруны тәэмин итәргә;

район (шәһәр) судлары өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә, шулай ук Үзәк округ хәрби суды өчен исемлекләргә һәм запас исемлекләргә үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне бастырып чыгарылганнан соң бер атна эчендә Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсенә әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр бастырып чыгарылган тиешле массакүләм мәгълүмат чарасының атамасы, бастырып чыгарылу вакыты һәм номеры турында мәгълүмат җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тиешле муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары тарафыннан әлеге боерыкның 1 пункты үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының антлы утырышчылар кандидатлары исемлекләренә һәм запас исемлекләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару белән бәйле чыгымнарын федераль бюджеттан

субвенцияләр хисабыннан үз вакытында финанслауны законнарда билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның 1 һәм 2 пунктлары үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «27» гыйнварындагы
21 номерлы боерыгына
кушымта

Форма

____________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы күрсәтелә)

**муниципаль берәмлегеннән**[1]

____________________________________________________________
(антлы утырышчы булуга кандидатлар исемлегенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә торган суд атамасы күрсәтелә )

# антлы утырышчы булуга кандидатлар исемлегенә (запас исемлеккә) үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Антлы утырышчы булуга кандидатлар исемлегеннән (запас исемлектән) чыгарылган гражданнар

| Т/с | Фамилия-се | Исеме | Атасының исеме | Жен-несе[2] | Туган вакыты[3] | Индекс | Торак пункт[4] | Урам[5] | Йорт | Кор-пус | Квар-тира |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

2. Антлы утырышчы булуга кандидатлар исемлегенә (запас исемлеккә) кертелгән гражданнар

| Т/с | Фамилия-се | Исеме | Атасының исеме | Жен-несе | Туган вакыты | Индекс | Торак пункт | Урам | Йорт | Кор-пус | Квар-тира |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

3. Фамилиясен һәм яшәү урынын үзгәрткән гражданнар – антлы утырышчы булуга

| Т/с | Фамилия-се | Исеме | Атасы-ның исеме | Же-несе | Туган вакыты | Индекс | Торак пункт | Урам | Йорт | Кор-пус | Квар-тира |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

_____________________________________________ башлыгы

(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы, Ф.И.А.и., имза)

[1] Алфавит тәртибендә MS Excel форматындагы таблица рәвешендә район (шәһәр) суды, Казан гарнизон хәрби суды һәм 101 нче гарнизон хәрби суды (исемлек һәм запас исемлек) өчен аерым-аерым төзелә.
[2] Кыскартылган билге – и. яисә х. бирелә.
[3] КК.АА.ЕЕЕЕ (мәсәлән, «12.05.1967») форматында бирелә.
[4] Торак пунктның төре өчен кыскартылган билге күрсәтелә (мәсәлән, ш. – шәһәр, а. – авыл, п. – поселок, штп – шәһәр тибындагы поселок, т/ю ст. п. –тимер юл станциясе поселогы, а. – авыл, ст. - станция).
[5] Торак пунктлардагы урамнар һәм урам-юл челтәренең башка элементлары һәм планлаштыру структурасы элементларының кыскартылган билгесе күрсәтелә (мәсәлән, бул. - бульвар, мкр-н - микрорайон, я.б. – яр буе, тк - тыкрык, мд. - мәйдан, просп. - проспект, ур. – урам).